**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_14.03.2023__ __263-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыкларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы комиссиясе турында» 2022 елның 17 мартындагы 197-п номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәнең 1.3 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәве һәм бирү тәртибе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 6 июнендәге 527 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәве һәм бирү, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү тәртибе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә

үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясенең составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга:

Игнашева Анна Вячеславовнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече – Комиссия секретарен;

Пестова Екатерина Николаевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгечен;

Ткачук Алексей Ивановичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Чинарев Алексей Михайловичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының минераль-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын.

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Федорова Регина Анатольевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесен – Комиссия секретарен;

Фазлыева Элина Марат кызын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгечен;

Вахитова Елена Камил кызын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Тюплина Юлия Константиновна – мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохит мониторингы бүлеге башлыгын.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибен раслау турында» 2022 елның 15 мартындагы 192-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 31 августындагы 755-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда, файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм файдалану хокукын чикләү тәртибенең 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның

6 июнендәге 522 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибе» сүзләре белән алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, туктатып тору һәм чикләү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан түбәндәгеләрне чыгарырга:

Ткачук Алексей Ивановичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Чинарев Алексей Михайловичны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының минераль-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгын.

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Вахитова Елена Камил кызын – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Федорова Регина Анатольевнаны – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесен.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков